**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2018 елның 27 гыйнварындагы ПУ-109 номерлы, 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2020 елның 21 июлендәге ПУ-432 номерлы, 2020 елның 25 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2021 елның 21 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2022 елның 8 июлендәге ПУ-470 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 19 июнендәге 412 номерлы, 2024 елның 8 июлендәге 522 номерлы, 2024 елның 7 августындагы 611 номерлы һәм 2025 елның 27 июнендәге 506 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясе турында нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Россия Федерациясе гражданнарына бирелә торган премияне акчалата бүләк, диплом һәм почет билгесе тәшкил итә.

Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә торган премияне акчалата бүләк һәм диплом тәшкил итә.

Премия гражданнар төркеменә бирелгәндә диплом һәм почет билгесе лауреатларның һәрберсенә тапшырыла, ә акчалата бүләк алар арасында бертигез бүленә.»;

б) Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составында:

Комитет составыннан З.Р. Вәлиеваны, С.А. Коноваловны, Р.М. Нургалиеваны чыгарырга;

Комитет составына кертергә:

Комитет секретаре итеп раслап, Нефедова Мария Владимировнаны – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесен (килешү буенча);

Рәхимов Илнур Сөләйман улын – «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директорын (килешү буенча);

Комитет рәисе итеп раслап, Терентьев Александр Михайловичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.А. Александровскаяның – «Казан шәһәре Совет районының «А.С. Пушкин исемендәге 93 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, «Татарстан Республикасының рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Россиянең традицион рухи-әхлакый хәзинәләрен саклау һәм ныгыту комиссиясе рәисе (килешү буенча)»;

И.И. Бикеевның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең беренче проректоры, фәнни эш буенча проректоры (килешү буенча)»;

Ә.Ф. Вәлиеваның – «АК БАРС СОЗИДАНИЕ» хәйрия фонды директоры, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының социаль мәсьәләләр һәм сәламәтлек саклау комиссиясе рәисе (килешү буенча)»;

Л.Н. Мишинаның – «Россия Пенсионерлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 05 март
№ 174